ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

11.06.2021 Олы Кайбыч ав. № 208

Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 2021елның 04 мартындагы 77 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Үзгәрешләр кертү зарурлыгына бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2021елның 04 мартындагы 77 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2. статьяның 2 пунктындагы в) пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларны электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре, шулай ук күпфункцияле үзәкләрдә административ процедураларны башкару үзенчәлекләре. Бүлектә гомуми билгеләре белән берләштерелгән мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләренә күрсәтелгән хезмәт күрсәтү тәртибен үз эченә алган муниципаль хезмәт күрсәтү вариантлары, шул исәптән алар алган муниципаль хезмәт нәтиҗәсенә карата да, булырга тиеш.»;

1.2. Тәртипнең 2 бүлеген түбәндәге эчтәлекле 2.2.1 пунктчасы белән тулыландырырга:

1.3. «2.2.1. Административ регламентның структурасы, мәгълүмат технологияләре өлкәсендә норматив-хокукый җайга салуны гамәлгә ашыруга вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы билгеләгән таләпләр нигезендә, мондый хезмәт күрсәтү процедураларын автоматлаштыруны тәэмин итә торган

тиешле хезмәт күрсәтү процедураларын машинада укыла торган тасвирлауны күздә тотарга тиеш.»;

1.4. III бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. Административ регламентлар проектларын эшләүгә гомуми таләпләр

3.1. Административ регламент проектын эшләүне муниципаль хезмәт күрсәтүче орган гамәлгә ашыра.

3.1.1.Җирле үзидарә органнарының административ регламентлар проектларын эшләү һәм килештерү Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре реестрын, муниципаль хезмәт күрсәтүләр реестрын электрон рәвештә алып баруны тәэмин итә торган дәүләт мәгълүмат системасында һәм (яисә) муниципаль мәгълүмат системасында гамәлгә ашырыла.

3.1.2. Җирле үзидарә органнарының административ регламентларын эшләүне һәм килештерүне тәэмин итә торган региональ дәүләт мәгълүмат системасы һәм күрсәтелгән системадан файдалану турында Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы карарлары булган очракта, әлеге пунктта күрсәтелгән административ регламентлар проектларын эшләү һәм килештерү мондый мәгълүмат системасында гамәлгә ашырыла.

3.2. Административ регламентлар проектлары бәйсез экспертиза һәм җирле үзидарәнең вәкаләтле органы үткәрә торган экспертиза узарга тиеш.

3.3. Җирле үзидарә органнары әлеге статьяның 3.2 пунктында каралган экспертизалар үткәрү максатларында үз региональ мәгълүмат системаларын һәм Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре реестрларын һәм муниципаль хезмәтләр реестрларын алып бару максатларында төзелгән муниципаль мәгълүмат системаларын кулланырга хокуклы.

3.4. Вәкаләтле җирле үзидарә органнары уздыра торган административ регламентлар проектларына экспертиза предметы булып административ регламентлар проектларының аларга карата 210-ФЗ номерлы Федераль закон белән куела торган һәм аның нигезендә кабул ителгән башка норматив хокукый актлар таләпләренә туры килүен бәяләү тора.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге http:// kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы
Башкарма комитет
Җитәкченең беренче урынбасары Э. Х. Заһидуллина